СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

05.02.2026 Баулы шәһәре № 27

Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә Баулы авыл җирлекләренең һәм Баулы шәһәренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 9 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 17 пункты нигезендә, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә, Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Баулы муниципаль районының авыл җирлекләренең торак пунктлары һәм Баулы шәһәренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча тапшыру турында шәһәр һәм авыл җирлекләре Советларының карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының авыл җирлекләре һәм Баулы шәһәренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә кабул итәргә.

2. Баулы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында

килешүләрне Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына авыл җирлекләренең һәм Баулы шәһәренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә юл эшчәнлеге буенча кабул итү-тапшыру турында килешүләр төзергә.

3. Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында килешү Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына авыл җирлекләренең һәм Баулы шәһәренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә юл эшчәнлеге буенча кабул итү-тапшыру турында килешү рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматныд рәми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров